ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

14.11.2019　　с. Верхний　Услон　　1161

**Югары Ослан муниципаль районында
даими эшләүче штаттан тыш
хәрби-табиб комиссиясе төзү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, запаста торучы хәрби хезмәткә керүче гражданнарны, запастагы офицерларны оештыру һәм гражданнарны үз вакытында медицина тикшерүе уздыру максатларында

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының хәрби комиссарына тәкъдим итәргә:

- даими эшләүче штаттан тыш хәрби-табиб комиссиясен булдырырга,
- 2019 елның 1 декабреннән 2020 елның 30 ноябренә кадәр штаттан тыш даими эшләүче хәрби-табиб комиссиясе эшен оештырырга.

2. «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына даими эш урыны буенча уртача айлык хезмәт хакын саклап калып, белгечләрнең, урта медицина персоналының кирәкле санын бүлеп бирергә:

- даими эшләүче штаттан тыш хәрби-табиб комиссиясе (төп һәм резерв составы) составында эшләү өчен,
- контракт буенча хәрби хезмәткә кергән, запастагы гражданнарга, запас офицерларына стационар тикшерү өчен койка-урыннар бүлеп бирү, бу максат өчен аеруча җаваплы табиб-белгечләрне беркетү һәм тулы һәм сыйфатлы тикшерү тәэмин итү.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына чираттагы медицина таныклandыруы өчен хәрби хезмәткә кергән, запастагы гражданнар, запас офицерларының килүен оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　　　　　В.С. Тимиряев**